БАЛТАСИНСКИЙ РАЙОННЫЙ
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАЛТАЧ РАЙОН
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«23» 05 2025 ел № 161

Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы мәгариф оешмалары җитәкчеләрен (директорларны, мөдирләрне) һәм житәкче вазифасына дәгъва кылучыларны аттестацияләү тәртибе һәм сроклары турында Нигезләмәне раслау хакында

«Россия Федерациясендә мәгариф турында» 2012 елның 29 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгынын 2014 елның 10 октябрендәге «Татарстан Республикасы белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы оешма җитәкчеләренә (директорларына, мөдирләренә) аттестация үткәрү тәртибе турындагы үрнәк Нигезләмәне раслау хакында» 6347/14 номерлы боерыгы, Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгынын 2017 елның 19 апрелендәге «Татарстан Республикасынын белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы оешма җитәкчеләренә (директорлары, мөдирләре) аттестация үткәрү тәртибенә үзгәрешләр кертү турында» 3822/17 номерлы хаты нигезендә Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты карар бирә:

1. Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районынын мәгариф эшчәнлеген гамәлгә ашыручы оешма җитәкчеләренә (директорларга, мөдирләргә) һәм җитәкче вазифасына дәгъва кылучыларга аттестация үткәрү өчен аттестация комиссиясе составын расларга. (1нче кушымта).

2. Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районынын мәгариф эшчәнлеген гамәлгә ашыручы оешма җитәкчеләрен (директорларны, мөдирләрне) һәм җитәкче вазыйфаларына дәгъва кылучыларны аттестацияләү тәртибе һәм сроклары турында Нигезләмәне (алга таба - Нигезләмә) расларга (2 нче кушымта).

3. Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитетының 2018 елның 17 апрелендәге «Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районынын муниципаль мәгариф учреждениеләре җитәкчеләренә аттестация үткәрү тәртибе турында»гы 122 номерлы карарын үз көчен югалткан дип танырга.

4. Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитетының 2019 елның 21 февралендәге «Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының муниципаль белем бирү оешмалары җитәкчеләренә аттестация үткәрү тәртибе турында» 2018 елның 17 апрелендәге 122 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында» 106 номерлы карарын үз көчен югалткан дип танырга.

5. «Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты мәгариф идарәсе» МКУны Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының белем бирү оешмалары җитәкчеләренә (директорларына, мөдирләренә) һәм җитәкче вазифасына дәгъва кылучыларга аттестация уздырырга вәкаләтле орган дип билгеләргә.

6. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты җитәкчесе урынбасарына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Балтач район башкарма комитеты
җитәкчесе                                                    А.Ф. Хәйретдинов

Татарстан Республикасы
Балтач район башкарма комитетының
2025 ел" 23 " 05
161 номерлы карарына
1 нче кушымта

Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының
белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы оешма житәкчеләренә (директорлар, мөдирләр)
һәм житәкче вазифасына дәгъва кылучыларга аттестация үткәрү өчен аттестация
комиссиясе составы

| | |
|---|---|
| Комиссия рәисе: | Мөхәрләмов Р.К.- «Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты мәгариф идарәсе» МКУ башлыгы; |
| Комиссия рәисе урынбасарлары: | Гайнетдинов И.Ф. - Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты житәкчесе урынбасары; |
| | Хәйруллина Р.Р. - «Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты мәгариф идарәсе» МКУнең укыту-методика эшләре буенча башлыгы урынбасары, комиссия рәисе урынбасары; |
| Комиссия секретаре: | Нургалиева Р.Н. - «Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты мәгариф идарәсе» МКУнең педагогларны һөнәри яктан үстерү буенча методисты; |
| Комиссия әгъзалары: | Абдрахманова Р.Р. - «Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты мәгариф идарәсе» МКУнең тәрбия эшләре буенча башлыгы урынбасары; |
| | Петрова Г.Н. - «Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты мәгариф идарәсе» МКУнең өлкән методисты; |
| | Г.Ф. Нотфуллина - «Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты мәгариф идарәсе» МКУнен мәктәпкәчә белем бирү буенча методисты; |
| | Гаязова Р. С. - Бөтенроссия мәгариф профсоюзының Балтач территориаль оешмасы рәисе; |
| | Әхмәдиева Э.Д. - «Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты мәгариф идарәсе» МКУнең баш белгече. |

Татарстан Республикасы
Балтач район башкарма комитетының
2025 ел "23" 05
161 номерлы карарына
2 нче кушымта

Татарстан Республикасы
Балтач муниципаль районының мәгариф эшчәнлеген гамәлгә
ашыручы оешма җитәкчеләрен (директорларын, мөдирләрен) һәм җитәкче вазыйфасына
дәгъва кылучыларны аттестацияләү тәртибе һәм сроклары турында НИГЕЗЛӘМӘ

## 1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Әлеге Нигезләмә Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы оешма җитәкчеләренә (директорларга, мөдирләргә)(алга таба- җитәкчеләр) һәм җитәкче вазифасына дәгъва кылучыларга аттестация үткәрү тәртибен (алга таба - җитәкчеләр) регламентлаштыра.

1.2. Белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы оешма җитәкчеләренә аттестация үткәрү тәртибен һәм шартларын билгеләү оешмаларны гамәлгә куючы компетенциясенә керә.

1.3. Җитәкчеләрне аттестацияләүнең максаты - аларның квалификация дәрәҗәсенең вазифа буенча квалификация характеристикасында билгеләнгән таләпләргә туры килүен билгеләү.

1.4. Җитәкчеләрне аттестацияләүнең төп бурычлары түбәндәгеләр:

- белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы оешма белән идарә итүнең нәтиҗәлелеген һәм сыйфатын арттыру;

- федераль закон таләпләрен, мәгариф эшчәнлеген гамәлгә ашыра торган оешма җитәкчеләре вазыйфасы буенча квалификация характеристикаларын исәпкә алу;

1.5. Аттестациянең төп принцибы - мәгариф эшчәнлеген гамәлгә ашыручы оешма җитәкчеләре һәм җитәкче вазифасына дәгъва кылучы затлар өчен аны үткәрүнең мәҗбүрилеге.

1.6. Җитәкчеләрне һәм җитәкче вазифасына дәгъва кылучы затларны аттестацияләү, кагыйдә буларак, алар белән хезмәт килешүе төзегәнчегә кадәр, башка очракларда хезмәткәр өчен хезмәт шартнамәсе шартлары белән билгеләнгән сынау срогы тәмамланганчыга кадәр уздырыла.

1.7. Аттестация комиссиясенең уңай карары кабул ителгән очракта, җитәкчеләр үз вазифасына билгеләнеп куела. Алар һәр 3 ел саен аттестация үтә.

1.8. Җитәкчеләрне һәм җитәкче вазифасына дәгъва кылучыларны аттестацияләү мәҗбүри.

## II. Аттестация үткәрү тәртибе

2.1. Җитәкчеләрне аттестацияләү гамәлгә куючы тарафыннан төзелә торган аттестация комиссиясендә уздырыла.

Гамәлгә куючыны тәкъдим итүче мәгариф бүлеге җитәкчесе аттестация комиссиясе тарафыннан законнарда билгеләнгән таләпләрне үтәгән өчен һәм һәр аттестация хезмәткәре буенча карарлар кабул иткәндә белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы оешма җитәкчеләре вазифалары буенча квалификация характеристикаларын үтәгән өчен җаваплы.

2.2. Җитәкче вазифасына дәгъва итүче аттестация комиссиясенә, вазифасы буенча квалификация характеристикасында билгеләнгән таләпләргә туры килүен раслау максатында, аттестация үткәрү өчен гариза (1 нче кушымта) һәм шәхси мәгълүматларны эшкәртүгә ризалык (2 нче кушымта) тапшыра.

Җитәкче вазыйфасына дәгъва кылучы затлар гаризага хезмәт кенәгәсеннән таныкланган өземтәне теркәп куялар.

2.3. Аттестация барышында җитәкчеләр үзләре җитәкче вазифасы буенча хезмәт эшчәнлеген гамәлгә ашыруга бәйле мәсьәләләр буенча тест рәвешендә квалификация сынаулары уза.

Тест ярдәмендә тикшерү аттестация комиссиясе вәкилләре катнашында уздырыла. Тест 1 сәгать дәвам итә (астрономия сәгате). Аттестация узучыга сорауларга язмача җавап бирергә тәкъдим ителә (һәр дөрес җавап 1 балл) һәм бер мөмкинлек бирелә. Тест вакытында мобиль телефоннардан, методик әдәбияттан файдалану тыела. Тест нәтиҗәләре беркетмә белән рәсмиләштерелә һәм аттестация комиссиясе әгъзалары тарафыннан таныклана. Нәтиҗәләр аттестация узучыларга җиткерелә.

Тест нәтиҗәләрен уңай исәпкә алу өчен кирәкле минималь өлеш 100% тан 70% ны тәшкил итә.

2.4. Аттестация комиссиясенә тест нәтиҗәләре турында документ тапшырылгач, аттестацияләнүче хезмәткәргә «Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитетының мәгариф идарәсе» МКУ башлыгы имзасы белән тәкъдимнәр рәсмиләштерелә (4 биттән артмаска тиеш), ул гамәлгә куючы буларак тәкъдим ителә (3 нче кушымта).

Күрсәтмәне әзерләгәндә аттестацияләнүче хезмәткәрдән элеккеге эш урыныннан тәкъдимнәр, характеристикалар, аның хезмәт эшчәнлеген характерлаучы башка документлар таләп ителергә мөмкин.

Эшләүче җитәкчене тәкъдим итүдә һөнәри, эшлекле сыйфатларны, хезмәт шартнамәсе белән йөкләнгән хезмәт бурычларын үтәү буенча җитәкче хезмәткәрнең һөнәри эшчәнлек нәтиҗәләрен төрлечә һәм объектив бәяләү булырга тиеш. Учреждениенең соңгы 3 елдагы эш нәтиҗәләренә (алдагы аттестация вакытыннан башлап); 3 елга учреждениене үстерү программасы; өстәмә гомумүстерү программасы мәҗбүри рәвештә ачыкланырга тиеш.

Аттестацияләнүче әлеге тәкъдим белән аттестациягә кадәр ике атна алданрак таныштырылырга тиеш, аны үткәрү срогы гамәлгә куючының күрсәтмә акты белән расланган график нигезендә билгеләнә. Тәкъдим белән танышканнан соң, теләк буенча җитәкче аттестация комиссиясенә аның һөнәри эшчәнлеген алдагы аттестация вакытыннан бирле характерлаучы өстәмә белешмәләрне (беренчел аттестацияләгәндә - эшкә керү көненнән башлап) тапшырырга мөмкин.

Җитәкче хезмәткәр тәкъдим белән танышудан баш тарткан очракта, эш бирүче һәм акт төзү барышында булган затлар (кимендә ике) тарафыннан имзаланган акт төзелә.

2.5. Аттестацияләнүче хезмәткәрнең гаризасы һәм тәкъдим итү аттестация комиссиясендә карала.

2.6. Аттестацияләнүче җитәкче аттестация комиссиясе утырышында шәхсән үзе катнашырга тиеш, бу хакта аттестация комиссиясенә язмача хәбәр итә. Аттестацияләнүче җитәкче җитди сәбәпләрсез аттестация комиссиясе утырышына килмәгән очракта, комиссия аттестация үткәрергә хокуклы.

2.7. Аттестация комиссиясе карары, аттестацияләнүче җитәкче булмаган очракта, аттестация комиссиясе утырышында катнашучыларның күпчелек тавыш бирү юлы белән кабул ителә. Аттестация комиссиясе әгъзаларының тавышлары тигез санда булган очракта, җитәкче аттестация узган дип санала.

Турыдан-туры аттестация комиссиясе утырышында катнашучы педагогик хезмәткәргә аттестация нәтиҗәләре аңа тавыш бирү йомгакларын ясаганнан соң хәбәр ителә.

2.8. Җитәкчене аттестацияләү нәтиҗәләре буенча аттестация комиссиясе түбәндәге карарларның берсен кабул итә:

- Квалификацион характеристикада билгеләнгән таләпләргә туры килә (вазыйфасы күрсәтелә);

- һөнәри әзерлекне уңышлы узу яисә квалификация күтәрү шарты белән квалификация характеристикасында (вазыйфасы күрсәтелә) билгеләнгән таләпләргә туры килә (белгечлек күрсәтелә);

- квалификация характеристикасында билгеләнгән таләпләргә туры килми (вазыйфасы күрсәтелә).

2.9. Аттестация комиссиясе карары беркетмә белән рәсмиләштерелә һәм аттестация үткәрү көнендә тавыш бирүдә катнашкан комиссия рәисе, рәис урынбасары, әгъзалары тарафыннан имзалана.

Зарурлык булган очракта, аттестация комиссиясе хезмәткәрнең һөнәри эшчәнлеген камилләштерү өчен аттестация комиссиясе карарына, аның белгечлеге буенча квалификациясен күтәрү кирәклеген һәм башка киңәшләрен кертә.

Күрсәтелгән тәкъдимнәр булганда, җитәкче аттестация уздырганнан соң бер елдан да соңга калмыйча аттестация комиссиясенә тәкъдимнәрнен үтәлеше турында мәгълүмат тапшыра.

2.10. Аттестация нәтиҗәләре турында аттестация комиссиясе карары «Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты мәгариф идарәсе» МКУ җитәкчесенең күрсәтмә акты белән расланa.

2.11. Идарә итү актының күчермәсе җитәкченең шәхси эшендә саклана.

## III. Аттестация комиссиясе карарларын гамәлгә ашыру.

3.1. Җитәкче вазифасына дәгъва кылучы әлеге вазифа буенча каралган квалификация характеристикасында билгеләнгән таләпләргә туры килми дип танылган очракта, аның белән хезмәт килешүе төзелми.

Җитәкчене аттестацияләү хезмәт шартнамәсе шартларында каралган сынау срогы тәмамланганчы үткәрелгән очракта, аттестация комиссиясенең тискәре карары булганда хезмәткәр белән шартнамә Россия Федерациясе Хезмәт кодексының 81 статьясындагы 1 өлешенең 3 пунктына таянып, Россия Федерациясе Хезмәт кодексының 71 статьясы нигезендә билгеләнгән тәртиптә өзелә.

3.2. Җитәкче аттестация комиссиясенең билгеле бер белгечлекне уңышлы узу яисә квалификация күтәрү өлешендә карарын (киңәшен) үтәмәгән очракта, гамәлгә куючы хезмәткәргә карата Россия Федерациясе Хезмәт кодексының 192 статьясы нигезендә дисциплинар түләтүләр кулланырга хокуклы.

3.3. Җитәкчеләрне аттестацияләү мәсьәләләре буенча хезмәт бәхәсләре Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә карала.

## IV. Аттестация комиссиясен төзү

4.1. Аттестация комиссиясе аттестация комиссиясе рәисеннән, аттестация комиссиясе рәисенең ике урынбасарыннан, аттестация комиссиясе секретареннән һәм аттестация комиссиясе әгъзаларыннан тора.

Аттестация комиссиясе рәисе:

1. Аттестация комиссиясе эшенә җитәкчелек итә;

2. Аттестация комиссиясе утырышларында рәислек итә;

3. Аттестация комиссиясе эше вакытында педагогик этика нормаларының үтәлүе өчен җавап бирә;

4. Аттестация комиссиясе эшенең сыйфаты, кабул ителә торган карарларның объективлыгы, эш йомгаклары буенча документларны вакытында рәсмиләштерү тәртибе өчен җавап бирә.

Аттестация комиссиясе рәисе урынбасары, аттестация комиссиясе рәисе булмаганда, аның функцияләрен үти.

Аттестация комиссиясе секретаре:

1. Календарь елга аттестация комиссиясе утырышларын үткәрү графигын эшли;

2. Аттестация комиссиясе әгъзаларына аттестация комиссиясе утырышын уздыруның срогы һәм урыны турында хәбәр итә;

3. Аттестация комиссиясе утырышын алып бара һәм рәсмиләштерә.

Аттестация комиссиясе әгъзалары:

1) Аттестация комиссиясе эшендә катнаша;

2) Карала торган мәсьәлә буенча үз фикерләрен әйтәләр (үзенчәлекле фикер булса, язма рәвештә);

3) Аттестация комиссиясе эше вакытында педагогик этика нормалары үтәлеше өчен җавап бирәләр;

4) Кабул ителә торган карарларның объективлыгы һәм компетентлыгы өчен җавап бирәләр;

5) Аттестация комиссиясе секретарен, җитди сәбәпләр аркасында аттестация утырышында катнашу мөмкинлеге булмаган очракта, утырышны уздыру датасына кимендә икс көн кала, кисәтәләр.

1 нче кушымта

____________________________________нә
**(аттестация комиссиясенең исеме)**

_______________________________________дән
**(фамилиясе, исеме, атасының исеме)**

____________________________________
**(вазифа һәм учреждение исеме)**

вазыйфасына дәгъва кылучы (яисә вазыйфага билгеләнгән)

# ГАРИЗА

Мине 20___елда вазифа буенча квалификация характеристикасы таләпләренә туры килүне билгеләү максатларында аттестацияләүне сорыйм

**(вазифа һәм учреждение исеме)**

Үзем турында түбәндәге мәгълүматларны хәбәр итәм:

Туган көн, ай, ел ______________________________________________

Белеме (кайчан һәм нинди һөнәри белем бирү учреждениесе тәмамлаган, алган белгечлек һәм квалификация)________________________________________

Дәүләт яисә муниципаль идарә, менеджмент һәм икътисад өлкәсендәге юнәлешләр буенча өстәмә һөнәри белем (яисә квалификация күтәрү курслары) ____________

Гомуми хезмәт стажы ________, шул исәптән педагогик эш стажы ________________

Җитәкчелек эше стажы _________ аттестацияләү үтә торган вазифада _______________.

Бу учреждениедә мин эшлим _______________елдан бирле эшлим (яки эшләмәдем).

Хезмәт кенәгәсеннән (җитәкче вазифасына дәгъва итүчеләр өчен) өземтә* китерәм. Түбәндәге бүләкләр, исемнәр, гыйльми дәрәҗә, гыйльми исем бар

Мәгълүмат-коммуникация технологияләренә ия булу дәрәҗәсе (югары, канәгатьләнерлек, түбән) (кирәклесен билгеләргә)

Аттестацияне аттестация комиссиясе утырышында минем катнашымда(минем катнашудан башка) (кирәклесен билгеләргә)уздыруыгызны сорыйм

Белем бирү учреждениесе җитәкчесе вазифасына (җитәкче вазифасына дәгъва кылучы) карата квалификация характеристикасы таләпләре буенча аттестация тәртибе белән таныштым.

" " 20____ел Имза

телефон номеры

2 нче кушымта

Житәкче вазыйфасына кандидатның шәхси мәгълүматларын эшкәртүгә ризалыгы

______________________________________________________________

(*муниципаль белем бирү оешмасы исеме*)

Мин, ______________________________________________________,

(*фамилиясе, исеме, атасының исеме*)

адрес буенча теркәлгән ________________________________________,

______________________________________________________________

паспорт сериясе __________ N __________, бирелгән

______________________________________________________________

______________________________________________________________

«Татарстан Республикасы Балтач районы башкарма комитеты мәгариф идарәсе» муниципаль казна учреждениесенең Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы муниципаль мәгариф оешмалары житәкчеләрен һәм житәкче вазыйфаларына кандидатларны аттестацияләү буенча аттестация комиссиясенә автоматлаштыру чараларын кулланып яисә кулланмыйча башкарыла торган теләсә нинди гамәлне (операцияне) яисә гамәлләр (операцияләр) җыелмасын эшкәртүгә (теләсә нинди гамәлне (операцияне) яисә гамәлләр (операцияләр) җыелмасын) түбәндәге персональ мәгълүматларны язу, системалаштыру, туплау, саклау, төгәлләштерү (яңарту, үзгәртү), алу, куллану, тапшыру (тарату, бирү, керү, блоклау, бетерү, юкка чыгару)): фамилиясе, исеме, атасының исеме, туу датасы һәм урыны, гражданлыгы; элекке фамилиясе, исеме, атасының исеме, датасы, урыны һәм аларның үзгәрү сәбәбе (үзгәртелгән очракта); хезмәт эшчәнлеге башланганнан бирле башкарыла торган эше (бергәләп эшләүне, эшкуарлык һәм башка эшчәнлекне кертеп), хәрби хезмәт; дәүләт бүләкләре, башка бүләкләр һәм мактау билгеләре (кем белән бүләкләнгән һәм кайчан); туган урыны, эш урыны һәм яшәү урыны (яшәү урыны) буенча теркәлү адресы булу); паспорт (серия, номер, кайчан һәм кем тарафыннан бирелгән), шулай ук хезмәт эшчәнлеген башкару мәсьәләләренә кагылышлы башка персональ мәгълүматларны эшкәртүгә ирекле рәвештә, үз ихтыярым белән һәм үз мәнфәгатемдә ризалыгымны бирәм.

Югарыда күрсәтелгән шәхси мәгълүматларны Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының муниципаль белем бирү оешмалары житәкчесе вазыйфасына кандидат буларак мәҗбүри аттестация узу максатларында эшкәртү өчен бирәм.

Мин шәхси мәгълүматларны эшкәртүгә ризалыкның әлеге ризалыкка кул кую датасыннан гамәлдә булуы белән таныштым. Биргән мәгълүматларның дөреслеге өчен җаваплылык турында кисәтелде. Шәхси мәгълүматларны эшкәртүгә ризалык ирекле рәвештә язылган гариза нигезендә кире алынырга мөмкин.

______________________ "____" ______________ 20____ ел.

(*имза*)

3 нче кушымта

## ТӘКЪДИМНАМӘ

___________________________________________________________

___________________________________________________________

*(учреждениенең исеме белән вазифасы,фамилиясе, исеме, атасының исеме)*

**үз вазифасы буенча квалификацион характеристика белән билгеләнгән таләпләргә туры килүен раслау максатыннан аттестацияләнә.**

### 1. Гомуми белешмәләр

| | | |
|---|---|---|
| 1.1 | Туу датасы (числосы, ае, елы) | |
| 1.2 | Белем турында белешмәләр (югары, кайсы һөнәри белем бирү учреждениесен тәмамлаган(а), тәмамлау датасы) | |
| 1.3 | Диплом буенча белгечлек | |
| 1.4 | Диплом буенча Квалификация | |
| 1.5 "Дәүләт һәм муниципаль идарә", "Менеджмент", "персонал белән идарә итү"әзерлек юнәлешләре буенча белем бирү | | |
| 1.5.1 | Әзерлек юнәлеше | |
| 1.5.2 | Уку йортының исеме | |
| 1.5.3 | Укытуның дәвамлылыгы | |
| 1.5.4 | Укуны тәмамлау датасы | |
| 1.6 Идарә эшчәнлеге профиле буенча квалификация күтәрү курслары: | | |
| 1.6.1 | Исем (курслар темасы) | |
| 1.6.2 | Мәгариф учреждениесенең исеме | |
| 1.6.3 | Уку сәгатьләре саны | |
| 1.6.4 | Тәмамлау елы | |
| 1.7 | Гомуми хезмәт стажы (еллары) | |
| 1.8 | Педагогик эш стажы (еллар) | |
| 1.9 | Әлеге вазыйфада эш стажы (еллар) | |
| 1.10 | Әлеге учреждениедә эш стажы (еллар) | |
| 1.11 | Хезмәткәр аттестацияләнә торган вазыйфага билгеләнү датасы | |

### II. Һөнәри эшчәнлектәге төп казанышлар

| | | |
|---|---|---|
| 2.1 | Педагогик эшчәнлек буенча квалификация категориясе булу (категориясе, бирү турында боерык датасы) | |
| 2.2 | Бүләкләр булу (исеме, елы) | |
| 2.3 | Гыйльми дәрәҗә булу (исеме, елы) | |
| 2.4 | Башка һөнәри казанышлар | |

### III. Җитәкче вазифасына билгеләнү өчен алшартлар

3.1. "Мәгариф оешмасы җитәкчесе" һөнәри стандарты (квалификация характеристикасы) нигезендә төзелгән җитәкченең һөнәри, эшлекле сыйфатларына, һөнәри эшчәнлеге нәтиҗәләренә дәлилле, һәрьяклы һәм объектив бәя бирү (аттестацияара чор өчен)

___________________________________________________________

3.2. Вазифасы буенча тест нәтиҗәләре, документны раслый торган документ ______________

3.3. Аттестация комиссиясе өчен нәтиҗәләр һәм тәкъдимнәр:

*Квалификация характеристикасынд билгеләнгән таләпләргә туры килә (вазифасы күрсәтелә), әгәр һөнәри әзерлек яисә квалификация күтәрү уңышлы узган булса, квалификация характеристикасында билгеләнгән таләпләргә (вазыйфаның исеме күрсәтелә) туры килә, (махсуслашу күрсәтелә), квалификация характеристикасында билгеләнгән таләпләргә туры килми (вазифа күрсәтелә).*

3.4. Профессиональ эшчәнлекне камилләштерү өчен тәкъдимнәр:

1.

2.

Мәгариф идарәсе органы җитәкчесе __________ __________ (имзаның аңлатмасы)

(имза)

Мөһер урыны

Тәкъдимнамә белән таныштым ____________ 20__